ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАДЫБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАДЫБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2020 Кадыбаш авылы № 23

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

Яңа ел бәйрәм чараларын үткәрүнең, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затларның, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, "Янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 ноябрендәге 1062 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә:**

Кертергә :

1. 2020 елның 20 декабреннән 2021 елның 10 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим.

2. Махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда 1-3 класслы хәвефлелектәге пиротехник эшләнмәләрдән (бенгаль утларыннан, шапылдаклардан тыш) файдалану тыелган дип билгеләргә:

сәнәгать, транспорт инфраструктурасы объектлары (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линияле) чикләреннән 500 метрда,

торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары чикләреннән, кешеләр күп була торган объектлар, автомобиль юллары чикләреннән 50 метрда.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында беренчел янгын сүндерү чаралары белән җиһазланган пиротехник эшләнмәләр куллану урыннарын билгеләргә:

- Кадыбаш авылының көнбатыш читендә ТНВ-Амбар-авыл-кыр манарасы юллары чатында;

- Касай авылның көнчыгыш-төньяк читендә Иске Эсләк- Девәтернә- Касай юлы кисешендә;

алардан файдалануны, шул исәптән "Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында" 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәүне тикшереп торуны тәэмин итәргә һәм бу хакта халыкка хәбәр итәргә.

4. Халык, юридик затлар арасында, шул исәптән пиротехника әйберләрен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы затлар арасында әлеге карарны, шулай ук пиротехника әйберләрен сатканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү максатында аңлату эше уздыруны оештырырга;

5. Кадыбаш авыл җирлеге халык дружинасы командирына ирекле ярдәмчеләр һәм муниципаль янгын сүндерү хезмәте әгъзаларының тәүлек буе кизү торуын оештыру һәм янгын сүндерүгә җайлаштырылган техника белән чаралар комплексын гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

6. Тышкы янгынга каршы су чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга, шул исәптән төзек булмаган су чыганакларын ремонтлауны оештырырга, елның кышкы чорында су җыю башняларын, туңмый торган тишекләрдән табигый сулыкларны алу өчен, су чыганакларын кардан чистарту җайланмалары белән җиһазларга.

7. Халыкны турыдан-туры янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларында шәхси автотранспортны парковкага кертмәү турында мәгълүмат бирергә, кирәк булганда, су чыганакларына янгын сүндерү машиналарын кертүне кыенлаштыра торган автотранспортны эвакуацияләүне оештырырга.

8. Пиротехника әйберләрен кулланганда иминлек таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

9. 2021 елның 2 гыйнварыннан 10 гыйнварына кадәр чорда торак йортларда гражданнар белән профилактик әңгәмәләр үткәрүне оештыру максатында, дәүләт янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләре, ирекле янгын сагы әгъзалары, полиция хезмәткәрләре, торак-коммуналь инспекция хезмәткәрләре, халыкны социаль яклау идарәләре (бүлекләре) хезмәткәрләре исәбеннән профилактик төркемнәр төзергә, шул ук вакытта күпбалалы, имин булмаган гаиләләр, ялгыз өлкән гражданнар яшәгән урыннарга аерым игътибар бирергә.

10. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Х.Л.Закиров